ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.04.2015 г.Казань № 48

**Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында**

2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 30 сентябрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында” ПУ-636 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында” ПУ-701 номерлы Указы нигезендә **боерык бирәм:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында

белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетындагы (алга таба – Дәүләт комитеты) Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә түбәндәгеләр хакында аңлатырга:

Татарстан Республикасының Дәүләт комитетында Исемлеккә кертелгән вазифаны биләүче граждан, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтеннән куылганнан соң ике ел дәвамында, Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясенең ризалыгы белән, хезмәт шартнамәсе шартларында оешмаларда вазифалар биләү һәм (яки) әлеге оешмада бер ай дәвамында гражданлык-хокукый шартнамә (гражданлык-хокукый шартнамәләр) шартларында йөз мең сумнан артык бәяле эшләр башкару (әлеге оешмага хезмәтләр күрсәтү) хокукына ия, әгәр дә әлеге оешмада дәүләти (административ) идарәнең аерым функцияләре Дәүләт комитетындагы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса;

Татарстан Республикасының Дәүләт комитетында Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләгән граждан, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтеннән куылганнан соң ике ел дәвамында, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамәләр төзегәндә, эшкә алучының (эш бирүченең) вәкиленә үзенең соңгы хезмәт урыны турында белешмәләр бирергә бурычлы;

Татарстан Республикасының Дәүләт комитетында Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләгән гражданның Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтеннән куылганнан соң әлеге пунктның өченче абзацында каралган таләпләрне үтәмәве күрсәтелгән граждан белән әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) төзелгән хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамәне өзүгә сәбәп була.

3. Дәүләт комитетының 2014 елның 22 апрелендәге “Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында аларга билгеләнгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган, шулай ук аларны биләгәндә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында” 1 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Рәис С.Е.Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 22.04.2015 ел,
№ 48 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары.
2. Туристлык эшчәнлеген дәүләти җайга салу бүлеге башлыгы.
3. Туристлык продуктын алга этәрү бүлеге башлыгы.
4. Туристлык индустриясен үстерү бүлеге башлыгы.
5. Дәүләт программаларын үстерү һәм гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы.
6. Бухгалтерлык исәбе һәм дәүләт заказы бүлеге башлыгы.
7. Кадрлар һәм юридик эш секторы җитәкчесе.
8. Туристлык эшчәнлеген дәүләти җайга салу бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе.
9. Кадрлар һәм юридик эш секторының әйдәп баручы киңәшчесе.
10. Кадрлар һәм юридик эш секторының әйдәп баручы консультанты.
11. Бухгалтерлык исәбе һәм дәүләт заказы бүлегенең әйдәп баручы белгече.
12. Бухгалтерлык исәбе һәм дәүләт заказы бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече.